Каюм Насыйри

Каюм Насыри

www.каюмнасыйри.рф

# Китаб-әт-тәрбия

# Книга о воспитании



УДК 37.018.1
ББК 74.9
Н26

Книга издана при поддержке Комиссии при Раисе Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан

**Каюм Насыри**

Н26 Китаб-әт-тәрбия = Книга о воспитании. — Казань: Татарское детское издательство, 2024. — 232 с.

ISBN 978-5-6050160-2-1

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән әзерләнгән әлеге китап күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриненң кыйммәтле мирасын торгызу һәм популярлаштыруга багышлана. Укыту һәм тәрбия максатларын күздә тоткан басма тәрбиячеләргә, укытучыларга, сыйныф җитәкчеләренә һәм ата-аналарга тәгаенләнгән.

Книга, подготовленная при поддержке Комиссии при Раисе Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, посвящена приумножению и популяризации наследия выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри. Настоящее издание, выпущенное в воспитательных и учебных целях, предназначено для воспитателей, учителей, классных руководителей и родителей.

УДК 37.018.1
ISBN 978-5-6050160-2-1 ББК 74.9

© Татарское детское издательство, 2024

Просветительское издание

## Каюм Насыйри

# Китаб-әт-тәрбия

## Каюм Насыри

# Книга о воспитании

Казань 2024

Хөрмәтле хезмәттәшләрем!

Сез кулыгызга алган «Китаб-әт-тәрбия» китабы — татар халкының гасырлар дәвамында туплаган рухи байлыгының бик кадерле бер өлеше. Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын тирәнтен өйрәнгән һәм бөртекләп җыйган мәгърифәтче галим, педагог һәм язучы Каюм Насыйри халыкка аң-белем тарату, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерү юнәлешендә зур эш башкара. Мәгърифәтченең хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәте, эчке кичерешләре, тәрбия тәҗрибәсе чагылыш таба, халыкның педагогик мирасына өстенлек бирелә. Тәрбиядә халыкчанлык һәм гуманлылык — К. Насыйриның төп педагогик принцибы. Атаклы мәгърифәтче туплаган әлеге хәзинә игелекле, тырыш, гыйлемле, әдәпле, кешелекле буын тәрбияләүдә гаҗәеп файдалы һәм үтемле, чөнки аның нәсихәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләр, гасырлар узуга карамастан, бүген дә әһәмиятле, бүген дә көн үзәгендә. Бу җыентыкның тәрбия эшендә, белем алуга омтылыш булдыруда, гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен сеңдерүдә ярдәме бәхәссез. Уку-укыту, тәрбия, аң-белем тарату максатларында куллану өчен чыгарылган әлеге басма һәр укытучының, сыйныф җитәкчесенең, һәр тәрбиячесенең һәм гомумән һәр татар кешесенең өстәл китабына әйләнер, дип ышанабыз.

«Китаб-әт-тәрбия» хезмәте XIX гасырның икенче яртысында К.Насыйри үзе нигез салган әдәби телебездә язылган булуы белән дә кыйммәтле. Үгет-нәсихәтләрнең русчага тәрҗемәсе моннан гасыр ярым элек яшәгән бабаларыбыз сөйләшкән телне яхшырак аңларга ярдәм итә. Китаптагы иллюстрацияләр нәсихәтләргә тирәнрәк төшенергә, аларны җанлырак күзалларга булыша, безне татар теленең бай сурәтләү чаралары дөньясына сәяхәткә дәшә. Бу сәяхәт белем-мәгърифәт тарату, киләчәк буынга үтемле тәрбия бирү эшен камилләштерүдә яңа, кызыклы һәм файдалы сәфәр булсын! Бүгенге буын балаларын нәкъ менә тыйнаклыгы, итагатьлелеге, фикер сөрешенең ачыклыгы белән замандашларын да сокландырган К. Насыйриның бай мирасына таянып тәрбияләсәк иде.

Хәерле сәгатьтә!

*Илсур Һадиуллин,*
*Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры*

# КЕРЕШ СҮЗ

Күренекле татар мәгърифәтчесе, энциклопедист галим, сүзлекләр авторы Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия» китабына татар халкының буыннан-буынга тапшырылып килгән, тормышның әхлакый нигезен тәшкил иткән кагыйдәләр, үгет-нәсихәтләр тупланган. Әлеге үгет-нәсихәтләр, үз-үзеңне тоту нормалары, бер гасырдан артык вакыт узса да, актуальлеген һич югалтмаган. Киресенчә, алар бүген тагын да эчтәлеклерәк, мәгънәлерәк яңгырый.

«Китаб-әт-тәрбия» җыентыгы XIX гасыр ахырында берничә тапкыр басыла. Китапның халыкчан тел белән язылган булуы, балаларга үтемле тәрбия бирүе бу басманың популярлыгында мөһим роль уйный. Сез бүген кулыгызга алган китапта Каюм Насыйри хезмәтенең теле мөмкин кадәр үзгәрешсез тәкъдим ителә, бу исә халкыбызның XIX йөздә ничек сөйләшкәнен күзалларга, телебездәге үсеш-үзгәрешләрне күрергә, тоярга, чагыштырырга һәм хәтта сүз байлыгыбызны арттырырга мөмкинлек бирә. Нәсихәтләрнең русчага тәрҗемәсе басманың куллану даирәсен киңәйтер, татарча оригинал текст белән чагыштырып, шул чордагы татар әдәби телен күзалларга һәм аны яхшырак аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйбыз. Ә китаптагы матур, гыйбрәтле, заманча иллюстрацияләр атаклы Каюм бабай нәсихәтләренең асылын тирәнрәк аңларга этәргеч булып тора.

Кулыгыздагы китап «Китаб-әт-тәрбия» комплексының бер өлешен тәшкил итә. Әлеге комплекс басма китап һәм сайтны берләштерә. Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия» китабында тәкъдим ителгән үгет-нәсихәтләрне www.каюмнасыйри.рф сайтыннан да укырга мөмкин. Бу сайтта бөек мәгърифәтче турында да тулырак мәгълүмат таба аласыз. Мондый комплексны мәктәпләрдә дәрес вакытында да, сыйныфтан тыш чараларда да кулланырга була. Ата-бабаларыбыздан калган кыйммәтле бай мирасыбызны өйрәник һәм саклыйк!



*Беренче тәрбия*

## ҺӨНӘР — ЫШАНЫЧЛЫ БАЙЛЫК

Бер акыл иясе балаларга шундый нәсыйхәт биргән: «Әй кадерле балалар, минем киңәшемне тыңлагыз — һөнәргә өйрәнегез. Дөнья малы, акча бик ышанычсыз. Алтын-көмеш юлчыга бер куркыныч тудырса, йорт-җирдә яшәүчедән аны урларга мөмкиннәр яки ут чыгып, көлгә кала ала. Ә менә һөнәр — бер агым су кебек, бетмәс чыганак. Һөнәр иясе барлык байлыгын югалтса да, төшенкелеккә бирелми, авырлыкларга бирешми. Дусларым, моның буш сүзләр түгеллегенә ышаныгыз. Һөнәр үзләштерегез, тәртипкә өйрәнегез, гыйлемле булыгыз».




*Икенче тәрбия*

## ҮЗЕҢНЕ ЯМАНЛАГАН КЕШЕНЕ МАКТА

Аксакалга берәү үзенең зары белән килә: «Фәлән кеше, минем бозык эшләремне сөйләп, фәлән җирдә мине яманлаган», — ди. Аңа каршы карт: «Син аның яхшы эшләрен сөйләп, аны оялт», — дип җавап бирә.

Әй дустым, бу сиңа да акыл булсын. Кем дә кем сине ахмаклыгы аркасында гаепләп сөйләсә, аңа каршы син аны макта. Әгәр ул кеше икән — акылга килер һәм оялыр.


2+2=
F(x)=5x²/3+7x²+K

*Өченче тәрбия*

## ГЫЙЛЕМ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ БУЙГА ҺӘМ КЫЯФӘТКӘ КАРАМЫЙ

Бер падишаһның берничә улы була. Алар барысы да озын буйлы, йөзгә-биткә чибәр булып, араларыннан берсе генә зәгыйфь, кыска буе белән аерылып тора. Әтиләре аны яратмый һәм кимсетеп карый. Әмма аның бу баласы акыл иясе һәм бик белемле була. Бервакыт ул: «Әй әти, акыллы тәбәнәк кеше надан озын буйлыдан яхшырак түгелме? Әйберләрнең бәясе дә зурлыгына карап билгеләнми. Менә мунча ташлары бик эре, ләкин йөге — бер тәңкә, энҗе бик вак, бөртеге — ун тәңкә», — ди. Әтисе һәм аның вәзирләре моны ишетеп көлә һәм аның белән килешә.

Әй дустым, гыйлем һәм мәгърифәт буйга һәм кыяфәткә карамый шул.



*Бишенче тәрбия*[1]

## ТИЛЕ КҮЗСЕЗЛӘРДӘН, НАДАННАРДАН ГЫЙБРӘТ АЛ

Акыл иясе Локманнан: «Син зирәклеккә кемнән өйрәндең?» — дип сорадылар. Ул: «Аякларының кая басканын белмәгән сукырлардан», — дип җавап бирде…

Әй дустым, зирәк Локманның сүзләре турында яхшылап уйлан! Чөнки ахмаклар һәм наданнар билгесезлек һәм белемсезлек караңгылыгында адашалар һәм, сукырлар кебек, абыналар, киртәләргә юлыгалар, егылалар. Алар, ахырын уйламыйча, теләсә нәрсә сөйлиләр. Шуңа күрә акыл иясе зирәклекне наданнарны һәм ахмакларны күзәтеп туплаганын әйткән.

[1] Нәшрияттан: 4, 32, 47, 101, 109, 110 нчы тәрбияләр ниндидер сәбәпләр белән Каюм Насыйриның беренче (гарәпчә) басмаларына да кертелмәгән булган.



*Алтынчы тәрбия*

## НАДАН, ТИЛЕ ЯНЫНДА ЙӨРСӘҢ, ҮЗЕҢ ДӘ ШУҢА ОХШЫЙ БАРАСЫҢ

Бер хөрмәтле кеше улын тәрбияләү, укыту өчен галим остазга бирә һәм: «Әй камилләрдән камил остаз, бу баланы тәрбиялә, белем бир, акыллы һәм гыйлемле булсын», — ди. Укытучы күпмедер вакыт әлеге бала белән шөгыльләнә, әмма бернәрсә дә барып чыкмый. Ул аны кире әтисе янына кайтарып җибәрә һәм: «Бу бала, шулкадәр надан һәм сәләтсез, аны укыта-укыта хәтта үзем диванага әйләндем» — ди…



*Җиденче тәрбия*

## КЕШЕ ИМИНЛЕК ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕҢ КАДЕРЕН БЕР МИХНӘТКӘ ДУЧАР БУЛГАЧ БЕЛӘ

Бер падишаһ диңгез буйлап сәяхәт иткәндә, беренче тапкыр корабка утырган һәм йөзү вакытындагы гадәти булган авырлыклар белән таныш булмаган егетне күрде. Ул бертуктаусыз елый, куркуыннан калтырый. Күпме генә тынычландырып карасалар да, елаудан туктамады. Бу падишаһның күңелен төшерде. Анда бер гыйлем иясе бар иде, ул: «Әй, әфәнделәр, әгәр, рөхсәт итсәгез, мин егетне акылга утыртыр идем. Аны чыдамлыкка өйрәтә алырлык хәйлә беләм», — диде. «Белгәнеңчә эшлә», — дип җавап бирде падишаһ. Әлеге кешенең боерыгы белән егетне бәйләп, корабтан ташладылар, ике тапкыр суга чумдырып, корабка кире күтәрделәр. Ул үзен үлеп терелгәндәй хис итеп, хәзер тыныч кына утыра башлый. Падишаһка бу ошады һәм ул: «Синең хәйләң нидә, акыл иясе?» — дип сорады. Ул: «Бу егет беркайчан да диңгезгә чыкмаган, кешеләрнең ничек батуын белмәгән, шуңа күрә хәвефсез йөзүгә шатлана алмады», — дип җавап бирде. Кешеләр дә булган тынычлыгының, сәламәтлегенең кадерен бер михнәткә дучар булгач кына аңлый башлый.



*Сигезенче тәрбия*

## УРЫНСЫЗ САРАНЛЫК — ФАЙДАСЫЗ

Бер падишаһ улының атасыннан калган күп хәзинәсе бар иде. Ул киң күңеллелек һәм юмартлык күрсәтеп, үзенең гаскәр халкына, үз дәүләте кешеләренә сансыз байлык таратты. Бервакыт сүзен уйлап сөйләми торган киңәшчесе нәсыйхәт буларак: «Әй шаһзадә, элеккеге падишаһлар бу хәзинәне зур тырышлык белән туплаган һәм берәр файдалы әйбер, эш өчен хәзерләгәннәрдер. Син азрак кысыбрак тот, киләчәк алда, хәзинәнең кирәк вакыты килер», — диде. Шаһзадәгә аның сүзләре ошамады... «Тәмле ашарга-эчәргә, бүләкләр бирергә яратам, шуннан ни булган?! Мин ул хәзинәгә каравылчы булырга җыенмыйм», — диде. Әй дустым, урынсыз саранлык файдасыз.



*Тугызынчы тәрбия*

## ҮЗ КӨЧЕҢ БЕЛӘН ТАПКАН БЕР ТИЕНЕҢ ЧИТ КУЛ БИРГӘН МЕҢ ТИЕННӘН БӘРӘКӘТЛЕРӘК


Ике туган бар иде. Берсе падишаһка хезмәт итеп гомер кичерде. Икенчесе үзенең кул көче белән табыш итеп яшәде. Бервакыт падишаһ хезмәтендәге бай туганые: «Әй туганым, ник падишаһ хезмәтенә кермисен? Бу авыр эшләрдән котылыр идең», — диде. Аңа каршы икенчесе: «Син ник кул көчең белән эшләп гомер итмисең? Бу сине хурлыктан һәм кимсетелүләрдән коткарыр иде. Акыл ияләре үз икмәгеңне ашап өеңдә утыруың, кешегә алтын белән чигелгән билбау киеп хезмәт итүдән яхшырактыр дип юкка әйтмәгәндер...» — дип җавап кайтарды. Үз көчең белән тапкан һәр тиенең чит кул биргән мең тиеннән бәрәкәтлерәк.



*Унынчы тәрбия*

## ӘҢГӘМӘГӘ УРЫНСЫЗ ТЫГЫЛУ — ӘДӘПСЕЗЛЕК

Нуширван падишаһ сараенда бер төркем акыл ияләре фикер алышып утыралар икән. Ул мәҗлестә Бөзәрҗөмһөр дә булган. Әмма ул бер сүз эндәшмичә тыңлап кына утырган. Аннан: «Я, Бөзәрҗөмһөр, син бу сөйләшүгә нигә бер дә катнашмыйсың», — дип сораганнар. Бөзәрҗөмһөр: «Вәзирләр — табиблар: сәламәт кешегә дару бирмиләр. Сезнең фикерегезнең дөрес икәнен мин күрәм, шуңа күрә монда минем катнашуның кирәге юктыр», — дип җавап биргән. Әй дустым, Бөзәрҗөмһөрнең үз-үзен тотышы сиңа дөрес үрнәктер: хәтта акыл ияләре дә урынсыз җирдә кеше сүзенә катышмаган. Кешене бүлдереп сөйләү — начар холыктыр. Әгәр кеше сүзенә катышырга теләсәң — әңгәмәдәшләреңнең сөйләп бетергәнен көт!



*Унберенче тәрбия*

## ИГЕЛЕК ҺӘМ ЙОМШАКЛЫК БЕЛӘН МӘМЛӘКӘТЛӘР ЯУЛАНА

Искәндәр Румидан: «Мәшрикъ һәм Мәгъриб илләрен ничек итеп алдың. Элекке падишаһлар никадәр гаскәр, акча, һәм хәзинә түгеп тә ала алмаганнар иде», — дип сорадылар. Искәндәр: «Мәмләкәтләрне яуладым, әмма халкын рәнҗетмәдем. Алдагы падишаһларны яхшы яктан гына искә алдым», — диде. Әй дустым, тәрбия кешене бөек итә. Игелек һәм йомшаклык белән мәмләкәтләр яулана. Барысына да карата яхшы мөгамәләдә һәм мәрхәмәтле булырга кирәк, хәтта үз дошманнарың турында да начар сөйләүдән саклан.



*Уникенче тәрбия*

## ШИК-ШӨБҺӘ БЕЛӘН КЕШЕ ӨСТЕНӘ ГАЕП ТАГУ — ХАТА

Сарай кешеләреннән булган берәү падишаһтан: «Фәлән дәрвиш хакында ни әйтәсең? Кемнәрдер аны хурлыйлар», — дип сорады. Ул аңа: «Тышкы яктан караганда гаебен күрмим, әмма эче, күңеле — миңа билгесездер. Шуңа хөкем итә алмыйм», — дип җавап бирде. Әй дустым, фәкать үзеңнең шик-шөбһәң белән генә: «Бу кеше фәләндер», — дип гаеп ату — хата. Әлеге начар, хәрам эштән саклан.



*Унөченче тәрбия*

## АХИРӘТТӘ ЙӨЗЕҢӘ ЧЫГАРЛЫК ГАМӘЛЛӘР ЭШЛӘМӘ

Шәех Сәгъди болай дип сөйләгән: «Хаҗда Габделкадыйр Гилянины күрдем. Кәгъбәгә башын куеп яткан да: «Әй Ходаем, гафу кыл! Әгәр гафу итмәсәң, кыяматтә күзсез итеп каберемнән кубар: изге кешеләр арасында оятка калганымны күрмәсәм иде!» — дип такмаклый икән.

Әй дустым, бу дөньялыкта бер кечкенә генә гаебеңне дә кешеләр күзенә күрсәтергә ояласың. Кыяматтә, пәйгамбәрләр, изгеләр һәм бөтен дөнья халкы күз алдында гаепләреңне һәм гөнаһларыңны йөзеңә бәрсәләр, анда бит качарга урын булмаячак. Инде сиңа дәрес булсын: ахирәттә йөзеңә чыгарлык начар эшләр кылма. Габделкадыйр Гиляни кебек изге кешеләр шул кадәр курыккач, сиңа, миңа ни кала?! Иманлы булыйк.



*Ундүртенче тәрбия*

## ФӘКЫЙРЬЛӘРНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ, АЛАРНЫ ЯКЫН ИТҮ — ӘҖЕРЛЕ

Изге бер адәм падишаһны оҗмахка эләккән итеп, ә бер фәкыйрь суфыйның җәһәннәмдә газаплануын төшендә күрде. Сорады: «Бу падишаһ бу дәрәҗәгә ни рәвешле иреште дә, бу фәкыйрь суфый бу түбәнлеккә ни сәбәпле төште? Киресенчә була дип уйлый идек». Әйттеләр: «Падишаһ фәкыйрьләрне һәм дәрвишләрне сыендырган өчен оҗмахлы булды. Ә менә әлеге фәкыйрь падишаһлар янында яшәү сәбәпле җәһәннәмгә эләкте».



*Унбишенче тәрбия*

## КАРА КҮҢЕЛГӘ ҮГЕТ-НӘСИХӘТ ҮТМИ

Грек провинциясендә бер кәрванны талап, хисапсыз малларны алып киттеләр. Сәүдәгәрләр бик елаштылар, Аллаһ Тәгаләдән ярдәм сорадылар. Тик ни файда?! Ул кәрван эчендә Локман дигән зирәк кеше дә бар иде. Берәү аңа: «Я гыйлем иясе, караклар малларыбызны кире кайтарсын өчен, үзеңнең хикмәтле сүзләреңне әйтче», — дип мөрәҗәгать итте. Локман: «Аларга хикмәтнең тәэсире булмас», — диде. Ягъни ташка кадак кагып булмаган төсле, вөҗданы кара булган кешене дә сихер белән дә, яхшы сүз белән дә туры юлга күндереп булмый.

Әй дустым, вәгазьләр бар, үгет-нәсыйхәт бирүчеләр бар, тик аларның кайберләренең вәгазьләре һәм нәсыйхәтләре үтемле түгел. Вәгазьнең тәэсир итмәве күп очракта вәгазьченең дөрес кешене, дөрес урынны сайламавы белән бәйле.



*Уналтынчы тәрбия*

## АКЫЛЛЫ БӘНДӘ ӨЧЕН АДЫМ САЕН ГЫЙБРӘТ БАР

Зирәк Локманнан: «Син әдәпне кемнән өйрәндең?» — дип сорадылар. Локман: «Кешеләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгәнен аңладым. Андый гамәлләрдән сакландым, шул рәвешле әдәпкә өйрәндем», — диде.

Әй дустым, акыллы бәндәләр өчен адым саен гыйбрәтләр, вәгазьләр бар, алардан үзеңә дәрес ал.



*Унҗиденче тәрбия*

## КОРСАКНЫ КҮП ТУТЫРУ ФАЙДАГА ТҮГЕЛ

Бер дәрвиш кич белән бик күп ашап, сәхәргә кадәр бертуктаусыз намаз укый, дип сөйлиләр. Моны бер акыл иясе ишетеп: «Әгәр, бичара ярты кадак икмәк ашап ятып йокласа, күпкә яхшырак булыр иде» — диде.

Әй дустым, корсакны күп тутыру файдага түгел.



*Унсигезенче тәрбия*

## ҖАН ИЯЛӘРЕННӘН ГЫЙБРӘТ АЛЫП, ЗИКЕР-ТӘСБИХ ӘЙТЕП ЯШӘ

Шәех Сәгъди бер сәфәре вакытында, төн урталарында уянып китә, төнне бер юлдашының, читтәрәк, җырлап-елап, шигырьләр укып, күзен дә йоммыйча уздыруын күрә. «Бу нишләвең?!» — дип сорый. Аңа юлдашы: «Былбылларны күрдем: куактан куакка очып, аһ-зар кылалар. Киекләр таулардан әрнүле авазлар салалар. Бакалар суда ыңгырашалар. Төрле җанварларның тавышыннан урман гөрләп тора. Шундый фикергә килдем: барлык җан ияләре йокламыйча зикер-тәсбих әйткән бер вакытта, минем изрәп йоклап ятуым гөнаһ булмасмы?» — ди.



*Унтугызынчы тәрбия*

## ДӘРВИШКӘ ЗИННӘТ КИЛЕШМИ

Бер урманда, үлән һәм яфрак белән тукланып, бик озак еллар бер дәрвиш яшәгән. Бер падишаһ аның хәлен белергә барган һәм: «Я шәех, әгәр теләгең булса, шәһәрдә тор, гыйбадәт кылып, тыныч һәм рәхәт яшәрең өчен урын әзерләтәм. Синең шифалы сулышыңнан файда алыр һәм изге гамәлләреңә без дә иярер идек», — диде. Дәрвиш әлеге тәкъдимне кабул итмәде. Вәзирләр падишаһка: «Берничә көнгә ул дәрвишне шәһәргә алып килеп, бераз кунак итеп карасак дөрес булыр, күңеленә хуш килеп, бәлки торырга да риза булыр», — диделәр. Шулай итеп, теге дәрвишне шәһәргә чакырып китерделәр, сарайларның берсендә үзенә генә урын әзерләделәр. Анда үлгән кеше дә кабереннән торып утырырлык матурлык иде. Падишаһ дәрвишкә хезмәт күрсәтү өчен бер чибәр йөзле кәнизәк һәм бер матур егет җибәрде. Аннан соң ул ләззәтле ризыкларны татып карый башлады. Зәвыклы һәм йомшак киемнәр киде. Татлы эчемлекләр эчте, хуш исле җимешләр генә ашады. Кәнизәкнең гүзәллеген күреп, күз сала башлады. Бервакыт падишаһ дәрвишне барып күрергә карар кылды. Килеп күрсә, аның каршында бөтенләй башка кеше: куллары ак, йөзләре алсу, үзе тазарган. Ефәк мендәрләргә яткан, янында ай йөзле бер кәнизәк бөтерелеп кенә йөри, тавистай бер егет баш очында җилпәзә селкеп тора. Падишаһ хәйран калып: «Мин акыл ияләренә дә, дәрвишләргә дә бертигез хөрмәт белән карадым», — диде. Вәзирләрнең берсе аңа каршы: «Әй падишаһым, башкалар да фән белән кызыксынсын өчен, галимнәргә алтынны да, башка яхшылыкларны да кызганма. Дәрвишләргә килгәндә, аларга башка нәрсә уйлап тап — аларга зиннәт килешми», — дип киңәш бирде.




*Егерменче тәрбия*

## ТОРМЫШТА КАНӘГАТЬ БУЛЫП, ГЫЙЛЕМ ҖЫЙ

Мисыр шәһәрендә ике әмирзадә бар иде. Берсе гыйлем өйрәнде, икенчесе мал җыеп баеды. Берсе — галим, икенчесе Мисыр патшасы булды. Баеганы туганына кимсетү белән карады һәм: «Мин солтанлыкка ирештем, син һаман бер урында таптанасың», — диде. Галим булганы: «И туганым, Аллаһ Тәгаләгә шөкер итү минем бурычым, чөнки мин пәйгамбәребез мирасын өйрәндем, ә син фиргавен мирасына ия булдың», — диде.

Әй дустым, бу кыйссадан сиңа шуны аңлау кирәк: канәгать бул. Һичшиксез, гыйлем — пәйгамбәребез мирасы.

[1] Фараон, по поверьям мусульман, — олицетворение алчности и злобы.


30–50%
Углеводы
25–35%
Белки
25–35%
Жиры

*Егерме беренче тәрбия*

# КОРСАГЫҢ ТУЛГАНЧЫ АШАМА, АЗ БЕЛӘН КАНӘГАТЬ БУЛ

Иран падишаһы бер оста табибны пәйгамбәр галәйһис-сәламгә хезмәт күрсәтү өчен җибәрде. Әлеге табиб күп еллар гарәп илләрендә яшәде. Һичбер кеше аңа: «Мине дәвала», — дип, янына килмәде. Бер көн ул пәйгамбәр галәйһис-сәлам янына барды. «Фәлән кадәр көннәр монда торамын, миңа беркем мөрәҗәгать итми», — диде. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам: «Бу халыкның гадәтләре шундый: ашыйсылары килми торып — ашамаслар һәм тамаклары туяр-туймас торып китәрләр», — дип җавап кайтарды. Табиб: «Сәламәтлекнең нигезе шул лабаса», — дип, җирне үбеп китеп барды.

Әй дустым, корсагың тулганчы ашама, аз белән канәгать бул.



*Егерме икенче тәрбия*

## ҮЗ НӘФЕСЕН ҖИҢҮЧЕ ГЕНӘ БАҺАДИР БУЛА

Бер адәм гомерендә бик күп мәртәбә тәүбә итте, ләкин тәүбәсен һәрвакыт бозды. Бер аксакалга барып, бу турыда «Тәүбәмне тота алмый гаҗизләнәм», — дип сөйләде. Ул: «Минемчә, бәлаң шунда ки, син үзеңне ашауда тыелгысызлыкка өйрәттең, теләкләреңә каршы бармадың, ә нәфесне җиңү бик авыр эштер. Болай дәвам итсәң, аның колына әйләнерсең, ахыр чиктә ул сине изәр», — диде.

Әй дустым, дөньяда үз нәфесен җиңүче генә баһадир була.



*Егерме өченче тәрбия*

## ФӘКЫЙРЬЛЕК ТЕЛӘНЕП ЙӨРҮДӘН ХӘЕРЛЕРӘК

Бер фәкыйрь дәрвиш бик нык ачлыктан интеккән, өстенә кат-кат ямаган киемнәрен киеп, үлемен көтеп утыра икән... Дусларының берсе: «Ник болай утырасың? Бу шәһәрдә фәлән кеше бар, мохтаҗларга ярдәм итә. Әгәр синең дә хәлеңне белсә, ярдәм күрсәтми калмас», — диде. Теге фәкыйрь: «Сөйләмә. Кешедән теләнеп йөрүгә караганда фәкыйрьлектә үлү хәерлерәк», — дип җавап бирде.



*Егерме дүртенче тәрбия*

## НӘФЕСЕН ТЫЙМАГАН КЕШЕ АВЫРЛЫКЛАРГА ЧЫДАМЫЙ

Хорасан провинциясендә ике дәрвиш бар иде, бер-беренә юлдаш булып сәфәргә чыктылар. Боларның берсе ябык, әмма ураза тотып, ике көнгә бер мәртәбә авыз ача. Икенчесе таза гәүдәле, көн дә өч мәртәбә ашый. Бер шәһәргә килеп җиттеләр. Биредә аларны тотып, сез шымчыларсыздыр дип, хөкем итүчегә илттеләр, төрмәгә яптылар. Ике атна тикшергәннән соң, гаепсез икәнлекләрен белделәр. Чыгарып җибәрергә әмер бирделәр. Зинданга кергәч, теге сау-сәламәт дигәненең үлеп ятканын, ябыгының исән-сау икәнен күрделәр. Моңа бик гаҗәпкә калдылар. Хөкем итүче әйтте: «Әгәр дә киресенчә булса гаҗәп булыр иде. Чөнки бу кеше күп ашарга яраткан, озак ач тора алмаган һәм шунлыктан үлгән. Ә икенчесе сабыр булган, озак вакытлар ризыксыз яшәргә өйрәнгән һәм исән калган».

Әй дустым, нәфесен тыймаган кеше авырлыкларга чыдамый.



*Егерме бишенче тәрбия*

## КҮП АШАУ — ИСРАФ

Бер акыл иясе үзенең улын күп ашаудан тыйды: «Әй улым, күп ашама, ул кешене авыруга әйләндерә», — диде. Улы: «Әй әти, ачлык кешене үтерәдер, фәлән кеше ачтан үлгән диләр, күп ашап үлде дигәнне ишеткәнем юк» — дип җавап бирде. Атасы: «Алай да, улым, чама белән ашау кирәк. Күп ашап кеше үлмәсә дә, моннан файда да юктыр», — диде. Бу кыйссадан үзеңә дәрес ал, китап әйткән сүзне күңелеңә сеңдер.



*Егерме алтынчы тәрбия*

## БӘХЕТ БАЙЛЫКТА ТҮГЕЛ

Бервакытны бер фәкыйрь бик мохтаҗлыкка төште. Дусты: «Фәлән кеше бик бай адәмдер, әгәр синең мохтаҗ икәнеңне белсә, һичшиксез ярдәм итәр», — дип киңәш итте.

Ул: «Бәлки шулайдыр да, әмма мин аны белмим шул», — дип җавап бирде. Теге кеше: «Әйдә, мин үзем күрсәтәм аны сиңа», — диде. Бергә бардылар. Барып җиткәч, ишегалдында күңелсезләнеп, борчуга төшеп утыручы берәүне күрделәр. Фәкыйрь моның үзеннән дә бәхетсезрәк икәнен аңлап, бер сүз әйтмичә кайтып китте...

Моны озата барган теге кеше: «Ник кайтып киттең?» — дип сорады. Фәкыйрь: «Аның үзен күргәч, ярдәменнән баш тарттым?» — диде.




*Егерме җиденче тәрбия*

## БАЙЛЫК БОЗЫКЛЫККА ЮЛ АЧА

Муса галәйһис-сәлам киеме юклыктан, ялангач комга күмелеп яткан бер фәкыйрьне күрде. Фәкыйрь: «Я, Муса, дога кыл: Аллаһ Тәгалә миңа байлык бирсен, бу ярлылыгыма чыдарлыгым калмады», — диде. Муса галәйһис-сәлам дога кылды. Аз вакыт эчендә Аллаһ Тәгалә теге кешене бай итте.

Беркадәр вакыт уткәч, Муса галәйһис-сәлам аның белән тагын очрашты. Ул шау-гөр килүче бик күп халык җыелган урынны күреп: «Бу нинди тавыш, нәрсә булды?» — дип сорады. «Бу фәлән кеше, күп эчеп исергән дә, сугышып, бер кешене үтергән. Аны, хөкем итеп, җәза мәйданына алып баралар» — дип җавап бирделәр. Пәйгамбәр Аллаһ Тәгаләнең хикмәтләренә хәйран калды. «Кара инде, уйламый дога кылганмын», — дип үкенде, тәүбә итте.

Әй дустым, Аллаһ Тәгаләнең илаһи хикмәте бар: кемдер бай, кемдер фәкыйрь. Әмма бай яки фәкыйрь булк кешенең үз гамәленнән генә тормый. Канәгать булу кирәк.



*Егерме сигезенче тәрбия*

## СИННӘН МОХТАҖРАКЛАРНЫ, ГАРИПЛӘРНЕ КҮРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ

Шәех Сәгъди: «Беркайчан да заманаһың үзгәрүеннән зарланып еламадым. Әмма бервакыт аягыма кияргә булмады. Яланаяк Күфә мәчетенә килдем. Шунда бер аяксыз кешене күрдем һәм Аллаһ Тәгаләгә рәхмәт әйтеп, тәүбә кылдым. Никадәр ярлы булсаң да, сабыр итәргә кирәклеген аңладым», — дип үзе белән булган хәлне бәян итте. Әй дустым, бу кыйссадан син дә үзеңә дәрес ал.



*Егерме тугызынчы тәрбия*

## БАЛЫКЧЫ ҮЗЕНӘ НАСЫЙП БУЛМАГАН БАЛЫКНЫ ТОТА АЛМЫЙ

Бер хәлсез, авыру балыкчының кармагына бик зур балык эләкте. Ул балыкны тартып чыгара алмады — көче җитмәде. Балык кармакны өзеп качты. Башка балыкчылар, моны күреп, әрләделәр һәм шелтәләделәр: «Һи, ачык авыз, кармагыңа эләккән шундый балыкны ычкындырдың!» — диделәр. Балыкчы аларга: «Әй, егетләр, миңа насыйп булмагач, нишли алам? Димәк, балыкның гомере бетмәгән», — дип җавап кайтарды.

Балыкчы насыйп булмаган балыкны тота алмый.

Балыкның әҗәле җитмәсә, кармакка эләкми.



*Утызынчы тәрбия*

## БЕРӘҮНЕҢ КАЙГЫСЫН КҮРЕП, БЕРКАЙЧАН ДА СӨЕНӘ КҮРМӘ

Бер сәүдәгәр үзенең сәүдәсендә мең алтынын югалтты һәм улына: «Әй улым, бу серне кешегә әйтмә» — диде. Улы: «Синеңчә булыр, әтием. Ләкин бу серне яшерүдән безгә ни файда булыр?» — дип сорады. Атасы: «Байлыгыбыз киму һәм күршеләребезнең безнең кайгыбызга сөенүе кебек ике кайгы булмасын дип әйтәмен», — дип җавап бирде.

Әй дустым, кеше кайгысын күреп сөенү — начар гадәт, аннан саклан.



*Утыз беренче тәрбия*

## БЕРӘР НӘРСӘНЕ ТӘМАМ НИГЕЗЕНӘ ТӨШЕНЕП БЕЛМӘСӘҢ, БУ ХАКТА СҮЗ БАШЛАМА

Бик акыллы һәм игелекле бер егет бар иде. Берничә тапкыр галимнәр һәм акыл ияләре арасында утырды, әмма авызыннан сүз чыгармады. Атасы: «Әй улым, ник белгәнеңне сөйләмисең?» — диде. Улы: «Белгәнемне кешегә белдерсәм, галим икән дип, минем белмәгән нәрсәмне сорарлар да оятлы булырмын дип куркам», — дип җавап бирде.


Әй дустым, берәр нәрсәне тәмам нигезенә төшенеп белмәсәң, бу хакта сүз башлама.



*Утыз өченче тәрбия*

# БАЙ БАЛАЛАРЫН КЫРЫСРАК ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘК

Бер падишаһ үзенең улын остазга белем алыр өчен бирде. Ул падишаһның улын бик тырышып укытты, яман нәрсәләрдән тыйды, кайчак кыйнады. Бу бала түзә алмыйча атасына кайтып зарланды, тәнен ачып күрсәтте. Атасы, моңа борчылып, остазны чакыртты һәм: «Әй остаз, гади кеше балаларын бу кадәр җәфаламыйсың икән, нигә безнең балабызга бу кадәр мәрхәмәтсезлек күрсәтәсең?» — диде. Остаз: «Әй падишаһ, ул балаларның кылган начарлыклары шулкадәр куркыныч түгел, беркем дә алар үрнәгенә иярмәячәк. Әмма шаһзадә, падишаһ булганнан соң, рәхимсезлек һәм гаделсезлектән читтә тору өчен, явызлыкның нәрсә икәнен белергә тиеш. Әгәр дә инде хәким һәм аның балалары мәрхәмәтсезлек кылса, алар турында сүз илдән илгә китәр», — дип җавап бирде. Дәрәҗәле кешеләрнең һәм байларның балаларына, гади кешеләрнең балаларына караганда, тәрбия бирүдә һәм тәртипкә өйрәтүдә кырысрак булырга, ягъни бай дип узындырмаска, иркәләмәскә, артык ирек бирмәскә кирәк.


2 + 2 = 4
4 × 4 = 16
√(16)
16 1/4 16 4/1

*Утыз дүртенче тәрбия*

## ЯШЬ ЧАКТА АЛГАН ГЫЙЛЕМ ТАШКА ЧОКЫП ЯСАЛГАН БИЗӘК КЕБЕК

Әй дустым, балаларны кече яшьтән тәрбияләү зарур. Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәк кебек. Чыбыкны да нечкәрәк чагында бөгү уңайлырак. Оланнарны күп фәннәргә балачактан төшендерергә, бераз математиканы да өйрәтергә кирәк. Балаларга сабак укыту турында башка юлы тирәнрәк сөйләшербез.


[1] «Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәккә охшаш» мәгънәсендә.



*Утыз бишенче тәрбия*

## ТӘРБИЯ БЕР ҮК, ЛӘКИН СӘЛӘТЛЕЛЕК ТӨРЛЕ

Бер падишаһ улын укытырга остазга бирде һәм: «Әй остаз, бу бала синеке, үз укыту тәртибең буенча яхшы белем бир», — диде. Укытучы аңа башка балалар белән бер дәрәҗәдә белем бирде. Ләкин ул гади халык балалары җиткән дәрәҗәгә җитмәде. Падишаһ шелтә белдермәкче булды. Остаз: «Әй падишаһ, белем бер үк, ләкин сәләт төрле», — дип җавап кайтарды. Әй дустым, гади кеше балалары кайчагында бай оланнарыннан күпкә җитезрәк һәм акыллырак булалар. Шунлыктан бай балаларын укыту күпкә күбрәк тырышлык таләп итә, чөнки алар артык иркәләп бозылган.



*Утыз алтынчы тәрбия*

## КЕМ УЛЫ БУЛУЫҢ ТҮГЕЛ, ГАМӘЛЕҢ МӨҺИМ

Бер гарәп улына: «Кыямәт көнендә синнән кем улы дип сорамаслар, ә нинди файдалы гамәлләр кылдың дип сорарлар» — диде.



*Утыз җиденче тәрбия*

## БАЛАҢ БАР ИКӘН, АҢА ЯХШЫ ТӘРБИЯ БИРЕРГӘ ДӘ КИРӘК

Сәгъди атлы шәех бер риваять сөйләде: «Бер фәкыйрь адәм бар иде, гомерендә бала күрмәде, Аллаһ Тәгаләдән: «Әгәр улым булса, шушы өстемдәге киемемнән кала, барлык әйберемне сатып, фәкыйрь-ярлыларга өләшер идем», — дип сорап нәзер әйтә. Аллаһ Тәгалә аңа бер ул насыйп итә. Ул бик шатланып, әйткән сүзендә тора, фәкыйрьләргә бар байлыгын хәер итеп тарата. Берничә елдан, янә Шам сәфәреннән кайтканда, юлым шул шәһәргә туры килеп, ул кеше турында сораштым. Зинданда икәнлеген әйттеләр. «Ни сәбәпле ул анда?» — дип сорадым. «Улы бер вакыт хәмер эчеп сугышып, бер адәмне үтерде дә, шәһәрдән качты. Улын тапмагач, аның урынына атасын яптылар» — дигән җавап алдым.

Әй дустым, хәзерге вакытта да моңа охшаш вакыйгалар бар. Ни өчен болай килеп чыгамы? Балаларына тиешле тәрбия бирә алмаганга.



*Утыз сигезенче тәрбия*

## НӘФЕС ДОШМАННАН ЯМАНРАК

Бер олуг галим: «Дошманыңа күбрәк яхшылык эшләгән саен, аның шулкадәр явызлыгы кимер. Ә нәфес беләән киресенчә — булган саен күбрәк кирәк» — диде.




*Утыз тугызынчы тәрбия*

## ЯВЫЗ БӘХЕТТӘН САКЛАН

Кеше байлык өчен түгел, ә байлык кеше өчен. Бер акыл иясеннән: «Нәрсә ул яхшы бәхет, нәрсә ул явыз бәхет?» — дип сорадылар. Ул: «Яхшы бәхетне алга куеп яшәүчеләр тыйнак, гыйбадәттә, аз сүзле, кече күңелле, юмарт, шәфкатьле булырлар, ахирәтне онытмаслар, гыйбадәтне калдырмаслар, Коръән укырлар, биш вакыт намазны вакытында кылырлар, хәрамнан сакланырлар, изгелекне яратырлар. Явыз бәхет корбаннары, нәфесенә ияреp, күп сөйләшер, явызларны үз итәр, мал җыярга хирыс, начар холыклы, хәйләкәр, шәфкатьсез, саран булыр, үлемне онытыр» — дип җавап бирде.

Әй дустым, моннан үзеңә дәрес ал, явыз бәхеттән саклан.



*Кырыгынчы тәрбия*

## БЕРӘҮ СИҢА ИЗГЕ НӘСИХӘТ КЫЛСА, УЛ ӨЙРӘТКӘНЧӘ ГАМӘЛ КЫЛ

Муса галәйһис-сәлам Карунга: «Аллаһ Тәгалә сиңа мәрхәмәтле булды — сине бай итте. Инде син дә рәхмәтле бул һәм изгелек кыл», — дигән нәсыйхәт бирде. Карун Мусаның сүзен тыңламады. Малы-мөлкәте белән аны җир йотты.

Әй дустым, берәү сиңа изге нәсыйхәт кылса, җаның-тәнең белән аны тыңла — ул өйрәткәнчә гамәл кыл.



*Кырык беренче тәрбия*

## ТУПЛАГАН ГЫЙЛЕМЕҢ БЕЛӘН ГАМӘЛ КЫЛ

Әй дустым, гомерләрен мәгънәсез һәм заяга уздырып яшәүче ике төркем кешеләр бар. Беренчеләре акча һәм мал җыеп та, үзләре файдаланмас. Икенчеләре гыйлем алып та, аны гамәлендә кулланмас. Син дә бу кешеләрдән була күрмә.



*Кырык икенче тәрбия*

# ДУСТЫҢ БЕРВАКЫТ — ДОШМАНГА, Ә ДОШМАНЫҢ ДУСТЫҢА ӘЙЛӘНЕРГӘ МӨМКИН

Дустың бервакыт — дошманга, ә дошманың дустыңа әйләнергә мөмкин.

Һәрбер сереңне дустыңа сөйләмә, чөнки белмәссең, бервакыт аның дошманыңа әйләнүе бар. Дошманыңа начарлык эшләмә, бәлки бервакыт, дустыңа әверелер. Дустыңның дустына да ышаныч юк икәнен исеңдә тот. Ике дошман арасында сүз сөйләсәң, белеп сөйлә: әгәр дуслашсалар, оятка калуың бар.



*Кырык өченче тәрбия*

## ХӘТТА ДИВАР ЯНЫНДА СӨЙЛӘСӘҢ ДӘ, АКЫЛ БЕЛӘН СӨЙЛӘШ, ДИВАР АРТЫНДА КОЛАК БУЛМАСЫН

Дустың белән пышылдап сөйләш, сүзең дошманыңа ирешмәсен. Хәтта диварлар янында да сак булырга кирәк, аларның да колагы булырга мөмкин.

Дошманның киңәшен тоту — хата. Әмма гыйбрәт алып, гамәл кылсаң, тыңлауның гаебе юк.



*Кырык дүртенче тәрбия*

## КУӘТЕҢ БАРЫНДА ИЗГЕЛЕК КЫЛ

Көч-куәте барында изге гамәл кылмаган кеше, көчсезләнгәч авырлык күрер.



*Кырык бишенче тәрбия*

## ҖИДЕ ТӨРЛЕ КЕШЕДӘН КИҢӘШ АЛМА

Әй дустым, җиде төрле кешедән киңәш алма. Беренчесе — надан кешедән, чөнки ул, үзенең наданлыгы аркасында сине бутап, азгынлык юлына салыр. Икенчесе — дошманыңнан, аның сине һәлак итүе бар. Өченчесе — хөсетле һәм көнче кешедән, чөнки алар нигъмәтеңә зыян килүен теләр. Дүртенчесе — икейөзле кешедән. Ул гел синең белән ризалашыр. Бишенчесе — куркак кешедән, ул сиңа дөресен әйтергә җөрьәт итмәс. Алтынчысы — саран кешедән, чөнки аның уенда мал җыюдан кала башка уй юктыр. Җиденчесе — малга комсыз кешедән киңәш сорама, ул нәфесенә каршы бара алмас.



*Кырык алтынчы тәрбия*

# ИСЕМЕҢНЕ МАКТАП ТЕЛГӘ АЛСЫННАР


Халыкка икмәк-тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Исән чагында сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар.



*Кырык сигезенче тәрбия*

## САУЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛ

Әй дустым, үзеңнең саулыгың һәм үткәндәге сәламәтлегең белән масаеп — алданма. Гомер буе сау-сәламәт була алмыйсың. Саулыгыңның кадерен бел, үзеңне хайван дәрәҗәсенә төшермә.



*Кырык тугызынчы тәрбия*

## НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ

Әй дустым, ни чәчсәң, шуны урырсың, ягъни изгелек эшләсәң, ул сиңа — изгелек булып, явызлыгың явызлык булып кайтыр.




*Илленче тәрбия*

## САРАН КЕШЕ ҮЗ МАЛЫНЫҢ КАРАВЫЛЧЫСЫ ГЫНА УЛ

Әй дустым, саран кеше фәкать үз малының каравылчысы һәм варисларының хәзинәчесе генә, ягъни үз малын саклый, варисларына тапшыру өчен бары вакытын гына көтә. Мондый киңәшләрнең гарәпчәсе минем «Фәвакиһел-җөләса» китабында тупланган[1].

---

[1] Каюм Насыйриның 1884 елда чыккан шундый исемдәге китабы бар. Речь идёт о книге Каюма Насыри «Плоды собеседований по литературе», 1884 год.



*Илле беренче тәрбия*

## ЯМАН ХОЛЫКЛЫ КЕШЕГӘ ГАМӘЛЕҢ БЕЛӘН НӘСИХӘТ КЫЛ

Әй дустым, начар һәм явыз холыклы кешене сүзләр белән түгел, ә игелекле эшләр белән тәрбияләргә кирәк. Әлбәттә, син моны үзең дә яхшы аңлыйсың.



*Илле икенче тәрбия*

## ЯХШЫЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛМӘГӘН КЕШЕДӘН ЕРАК ЙӨР

Әй дустым, яхшылыкның кадерен белмәгән кешедән ерак йөр. Берәүгә бер яхшылыгың тисә — сөйләп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң — фаш кыл, онытма.



*Илле өченче тәрбия*

## ӘҖӘЛ КӨТМӘГӘНДӘ КИЛЕРГӘ МӨМКИН


Әй дустым, тәнең никадәр сау-сәламәт, үзең яшь булып, егәрлегең ташып торса да, тәүбәсез һәм васыятьсез ятып йоклама. Адәмнең әҗәле күз белән каш арасында, һич көтмәгәндә килергә мөмкин.



*Илле дүртенче тәрбия*

## САФ КҮҢЕЛЛЕ, КҮРКӘМ ФИГЫЛЬЛЕ КЕШЕ ХӨРМӘТ-ИХТИРАМГА ЛАЕК

Әй дустым, күршеләренә игътибар, ихтирам күрсәтмәгән кеше кадерле һәм хөрмәтле була алмас. Шулай ук туганнарына өлеш чыгармаган — малының рәхәтен күрмәс. Саф күңелле, күркәм фигыльле кеше генә хөрмәт-ихтирамга лаек.



*Илле бишенче тәрбия*

## ГАФУ ИТӘ БЕЛҮ — ИҢ КҮРКӘМ СЫЙФАТ

Әй дустым, бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, эчкерсезлегең белән үрнәк күрсәт, ягъни аннан үч алырга тырышма. Кешеләрнең сиңа китергән авырлыкларын онытып, аларның кылган изгелекләрен генә искә төшерү чын егетлек һәм кешелеклелек була. Гафу итә белү — иң күркәм сыйфат.



*Илле алтынчы тәрбия*

## МОХТАҖГА ҮЗЕ СОРАГАНЧЫ ЯРДӘМ КҮРСӘТ

Берәүнең мохтаҗ икәнен белеп, синнән өмет итә дип уйласаң — үзе сорамас борын ярдәм ит.



*Илле җиденче тәрбия*

## ИГЕЛЕГЕҢНЕ ИСКӘ ТӨШЕРМӘ

Әй, дустым, берәүгә күрсәткән игелегеңне, ярдәмеңне, яхшылыгыңны әйтеп, «Мин сиңа фәлән яхшылыклар эшләдем», — дип сөйләп йөрсәң, адәм тарафыннан рәхмәт, Аллаһ Тәгалә тарафыннан савап өмет итмә. Син исенә төшермәсәң дә, ул кеше үзе дә белә. Һәм Аллаһ Тәгалә дә синең кылган изгелекләреңне белә.



*Илле сигезенче тәрбия*

## ТАР КҮҢЕЛЛЕ КЕШЕНЕҢ РИЗЫГЫ ДА ТАР

Әй дустым, тар күңелле кешенең ризыгы да тар була ди. Киң күңелле һәм сабыр булырга тырыш. Туры сүзле кешенең матурлыгы артык кирәкмәс тә, сүзендә һәм фигылендә ихлас кешегә халык: «Һай, күркәм кеше икән», — дип сокланыр.



*Илле тугызынчы тәрбия*

## ХӘЛӘЛ КӘСЕПТӘН КИЛГӘН МАЛНЫ ХӘРАМГА САРЫФ КЫЛЫРГА ЯРАМЫЙ

Хәерле мал шул: хәләл юл белән килер; изге юлга сарыф кылыныр. Хәерсез мал шул: хәрам юл белән килеп, начарлык һәм әшәкелекләр юлына сарыф кылыныр.

Әй дустым, игелеклелек юлында хәләл кәсептән килгән малны хәрамга сарыф кылырга ярамый. Һәм аны хәрамга сарыф кылырга Аллаһ Тәгалә ирек бирми. Хәләлдән килгән акча һич тә хәрамга китмәс. Иясе андый малның игелеген үзе күрер, ул кеше үлгәнче бу байлыгыннан аерылмас. Ә хәрамнан килгән мал исә иясенә бәрәкәт китермәс. Ул хәрамнан килгән һәм кабат хәрамга китеп бетә; китә башласа, иясе аны туктата алмый, тиз вакыт эчендә мохтаҗлыкка төшә.



*Алтмышынчы тәрбия*

## СИҢА ИЗГЕЛЕК КЫЛГАН КЕШЕГӘ ЯМАНЛЫК ЭШЛӘМӘ

Әй дустым, белеп тор ки, сиңа изгелек кылган кешегә начарлык эшләмә, ризыгы белән бүлешкән кешене хурлама һәм кимсетүле караш белән карама, мәрхәмәтсез бәндә бәхетсезлек чокырына тиз төшә һәм дошманнары күп була. Мәрхәмәтсезлектән саклан.



*Алтмыш беренче тәрбия*

## ЗАЛИМНӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮЧЕ ЗАЛИМНӘРНЕҢ БЕРСЕ БУЛА

Залимнәрне өстен күрүче һәм аларга ярдәм итүче кеше — аларның берсе һәм адәмнәрнең иң явызы була. Әмма, дустым, мәрхәмәтсезлек, залимлек дигән нәрсә акча һәм башка дөньяви нәрсәләргә генә кагылмыйча, кешеләрнең сүзендә һәм фигылендә дә чагыла.



*Алтмыш икенче тәрбия*

## АКЫЛЛЫ БУЛЫП КЫЛАНЫП, УРЫНСЫЗ ҖИРДӘ НӘСИХӘТ КЫЛЫРГА МАТАШМА

Халык арасында берәүгә вәгазь һәм нәсыйхәт кылу — аның башына сугу кебектер. Һичшиксез, әлеге кеше синең дошманыңа әйләнер. Ул синең нәсыйхәтеңне тоту кая, хәтта сине харап итү юлын эзләр. Акыллы булып кыланып, урынсыз җирдә нәсыйхәт кылырга маташма.



*Алтмыш өченче тәрбия*

## АЛЫШ-БИРЕШ — БАШКА, КАРДӘШЛЕК — БАШКА

Әй дустым, туганнарча аралаш, ятларча мөгамәлә кыл. Ягъни алышта-бирештә: «Бу миңа туган тиешле кеше әле», — дип өстенлек күрсәтмә. Үзең өчен дә: «Мин кардәш кеше ләбаса, азрак ташлама ясa», — димә. Чөнки мал башка, кардәшлек башка, болай ташлама ясау ачу тотуга һәм дошманлыкка сәбәпче була. Әгәр яклау кирәк булганда да, аны алыш-биреш тәмам булгач эшләү тиеш.



*Алтмыш дүртенче тәрбия*

## ЯХШЫ ҺӘМ ЙОМШАК СҮЗГӘ КЕШЕНЕҢ КҮҢЕЛЕ ЭРЕП КИТӘ

Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырак һәм яманрак, ягъни тел белән әйтелгән ачы һәм кабахәт сүзләрнең адәмгә тәэсире тәнне пычкы белән кискәннән дә авыррак. Әй дустым, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, начар сүзләр әйтеп, йөрәген яралама. Кайвакыт гадәти генә сүзләр дә, башкаларга авыр ишетелергә мөмкин — каты телле булма. Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы: яхшы һәм йомшак сүзгә кешенең күңеле эри. Шуңа күрә авызыңны уйлап ач, ашыгып җавап бирмә!



*Алтмыш бишенче тәрбия*

## АШЫГЫП ЭШ КЫЛГАН КЕШЕ ҮКЕНЕЧКӘ ТАРЫМЫЙ КАЛМАС


Һәр эшнең ахырын уйлап башкарган кеше бәлага юлыкмас һәм кайгы күрмәс. Уйламыйча, ашыгып эш кылган кеше үкенечкә тарымый калмас.



*Алтмыш алтынчы тәрбия*

## БЕР ҖИРГӘ КЕРГӘНЧЕ, ӘҮВӘЛ АННАН НИЧЕК ЧЫГАСЫҢНЫ УЙЛА

Әй дустым, кереречңнән алда, чыгарыңны уйла. Бер ишекне ачканчы, ябасыңны исеңдә тот, ягъни бурычка алганчы, ничек итеп түләреңне кайгырт. Һәм гомумән, бер эшкә керешкәнче, аның азагын күзалла.



*Алтмыш җиденче тәрбия*

## БЕР МӘРТӘБӘ ЯЛГАНЛАСАҢ, ЧЫН СҮЗЕҢӘ ДӘ ЫШАНМАСЛАР...

Ялганчы дигән даны чыккан кеше, күпме чын сүз әйтсә дә, ышандырмый. Бер ялган сүз сөйләсәң, тугыз дөрес сүзеңә дә ышанмаслар.



*Алтмыш сигезенче тәрбия*

## ЯМАН ХОЛЫКЛЫ ЗАТЛАРДАН ЕРАК ЙӨР, КҮРКӘМ ХОЛЫКЛЫ ЗАТЛАРДАН АЕРЫЛМА

Әгәр вакчыл һәм түбән җанлылар, наданнар дәрәҗәләргә ирешсәләр, хөрмәтле, кешелекле адәмнәрнең кадере калмас.

Әй дустым, яман холыклы затлардан ерак йөр, күркәм холыклы затлардан аерылма.



*Алтмыш тугызынчы тәрбия*

## АВЫЗЫҢНАН ЧЫККАН КИРЕ КАЙТМАС

Әй дустым, әйткән сүз аткан ук кебек, һәрбер сүзне уйлап сөйләшергә кирәк, авызыңнан чыккан кире кайтмас. Гөнаһлы була торып та, тәүбәгә ашыкмаган кешенең кечкенә гөнаһы да зурга әйләнә.



*Җитмешенче тәрбия*

## АКЫЛ БЕЛӘН ТОТСАҢ, АЗ НӘРСӘ ДӘ БӘРӘКӘТЛЕ

Акыл белән тотсаң, аз әйбер дә бәрәкәтле була, ә уйламыйча тотып, исраф итсәң, күп булган әйберләр дә җитми.

Әй дустым, сиңа монда тәрбия шул: көнендә ун тиен файда алсаң, шуның сигез тиенен чыгымнарыңа тотып, калганы җыеп барылсын, гомергә фәкыйрь булмассың, мохтаҗлык күрмәссең. Әгәр ун тиен файда алып, унбер-унике тиенен чыгымга тотсаң, эшләрең хөрти барыр.

Безнең заманда андый очраклар бик күп булды. Файда алмаган көнне икмәк белән су ашап торсаң да ярар.

Әй дустым, акыллы кеше шул: булганын саклап тотар, бүгенге эшен иртәгәгә калдырмас.аклар, бу көнге эшен иртәгә калдырмас.



*Җитмеш беренче тәрбия*

## ХӨРМӘТ ҺӘМ ДАН ОЗЫН БУЙ, ЮАН КОРСАК БЕЛӘН ТҮГЕЛ, Ә ТЫРЫШЛЫК БЕЛӘН ЯУЛАНА

Хөрмәт һәм дәрәҗә — озын буй, зур корсак белән түгел, ә тырышлык белән яулана. Тырышлыктан кала барысы да череп туфракка әйләнә, олуглыкка илтми. Зур тырышлыгың һәм күркәм әхлагың булмыйча, буең, чибәрлегең, кыяфәтең белән дәрәҗәле булырга тырышу — гаять ахмаклык. Дәрәҗә һәм игелеклелек дигән нәрсә гыйлем, әдәп, күркәм әхлак белән килә. Алар булмаса, күл өстендә яхшы атлар юргалатып кына дәрәҗәгә һәм хөрмәткә ирешеп булмый.

Әй дустым, кеше булам дисәң, мондый юк эшләргә тырышлык куйма.



*Җитмеш икенче тәрбия*

## ГЫЙЛЕМ ИЯСЕ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ ИСЛЕМАЙ САТУЧЫ ЯНЫНДА ТОРГАН КЕБЕК...

Акыл ияләре һәм гыйлемлеләр белән аралашу ачылмаган күңелләрне уятыр. Гыйлемле һәм мәгърифәт ияләрен тыңлау ислемай сатучылар янында тору белән бер: гәрчә сиңа ул ислемай бирмәсә дә, хуш исе борыныңа керә. Наданнар һәм явызлар белән сөйләшү — тимерчеләр янында тору белән бәрабәр: очкыннары сиңа килеп чәчрәр, шулай ук наданның наданлыгы да сиңа тәэсир итә...



*Җитмеш өченче тәрбия*

## КЕШЕНЕҢ ЭШЕНДӘ ЯКИ СҮЗЕНДӘ ХАТА КҮРСӘҢ, ТӨЗӘТМӘ

Әй дустым, кешенең эшендә яки сүзендә хата күрсәң: «Һай хата кылдың, болай кирәк иде», — дип хатасын төзәтмә, акыл алса да, сине дошман күрер. Мондый хәлдә күп тапкырлар үземнең калганым булды: берничә мәртәбә кешенең хатасын дөресләп, үкенгәнем бар.



*Җитмеш дүртенче тәрбия*

## ФАЙДА КИТЕРЕРГӘ КУЛЫҢНАН КИЛМИ ИКӘН, ЗАРАРЫҢ БУЛСА ДА ТИМӘСЕН

Адәмнең табигате шундый ки, файдасы тигән кешене якын итәр, ә зарарын күргән кешегә рәнҗер. Әй дустым, файда китерергә кулыңнан килми икән, зарарың булса да тимәсен. Ачык йөзле, татлы сүзле бул, дустың күп булыр.



*Җитмеш бишенче тәрбия*

# МАЛНЫ САКЛАУ АНЫ ТАБУ БЕЛӘН ҖЫЮДАН АВЫРРАК

Әй дустым, мал табуның юллары бик күп. Нинди генә юл булмасын, малны хәләлдән табу фарыз. Хәләлдән килгән мал — тотрыклы була. Хәрам мал исә адәмгә йокмый; тиз кулыңнан китәр, җаваплылыгы һәм авырлыклары гына сиңа калыр. Әмма хәләлдән килгән малыңны саклап тот, хәрам җиргә сарыф итмә. Малны саклау — малны табу һәм җыюдан авыррак. Саклап тота белмәгәннәре сәбәпле никадәр байлар малсыз калдылар.



*Җитмеш алтынчы тәрбия*

## ЧЫГЫМНАРЫН САНАП ТОТКАН КЕШЕ МОХТАҖ БУЛМЫЙ

Әй дустым, байлыгыңны малның килүенә карап тот, керемеңә караганда чыгымнарың кимрәк булса, бу дөньяда һич мохтаҗлык кичермәссең. Һәр көн күпме-азмы чыгымнарыңнан артканы җыелып барсын, дәүләтең һаман артыр. Инде малың артып китсә, фәкыйрь вакытыңны онытма, ул чакта «Бу нәрсә бу көнгә җитсен», — дип сарыф кылган кебек, бай булгач, шундый ук хисап белән тот. Чыгымнарын санап тоткан кеше мохтаҗ булмый.



*Җитмеш җиденче тәрбия*

## ӘМАНӘТНЕ ҮЗ МАЛЫҢ КЕБЕК ИТЕП САКЛА

Әгәр бер дустың яки кардәшең малын яки хезмәтен сиңа ышанып тапшырса, үзеңнеке кебек итеп сакла һәм үз хезмәтең кебек итеп башкар. Шулай эшләсәң, Аллаһ Тәгалә синең малыңны бәрәкәтле итәр, халык арасында ышанычлы дигән исемең таралыр. Ләкин, дустым, байлыгыңны яки эшеңне берәрсенә ышанып тапшырырга уйласаң, исраф итүче адәмгә — комарбазга, ягъни отыш уеннарын уйнаучы кешегә һәм хәмер эчүчегә әманәт итмә.



*Җитмеш сигезенче тәрбия*

## КЕМГӘ БУРЫЧЛЫ БУЛСАҢ, ШУҢА КОЛЛЫККА ТӨШӘРСЕҢ

Әй дустым, бурычка кермә. Рибага һәм заклад биреп акча алма. Чөнки бу эшләр адәмне хурлыкка төшерер. Кемгә бурычлы булсаң, шуңа кол булырсың. Кешегә бурычка акча бирмә, бигрәк тә — дустыңа. Әгәр ул вакытында үзе белеп бирмәсә, сорарга туры килер, сорасаң рәнҗер, арагызда дуслык бетәр. Дустыңнан дошман ясау — наданнар эше.



*Җитмеш тугызынчы тәрбия*

## ӘГӘР БЕР КЕШЕ СИҢА ӘМАНӘТ БИРЕРГӘ ТЕЛӘСӘ, ҮЗЕҢӘ БӘЛА АЛМА

Әй дустым, әгәр бер кеше сиңа сакларга әйбер бирергә теләсә, кабул итмә, үзеңә бәла алма. Чөнки аның өч куркыныч ягы бар. Берсе — әманәт нәрсәне үз малларыңнан артыграк саклап интегәсең һәм хуҗасына кайтарып бирәсең. Яки кеше әйберен үзеңә алырга теләп, синнән әманәт алганым юк, дип сүзләрен кире кагарсың. Яки, ул әйбер югалса, авыр хәлдә һәм оятка калырсың. Каза күрдем, югалды дисәң дә ышанмаслар. Әйе, әманәт саклау — җиңел эш түгел. Әгәр сакларга әйбер кабул иттең икән, яхшы сакла һәм хыянәт итмә. Берәү әйберен сатарга сораса, сату белән үк тоткарлыксыз акчасын иясенә тапшыр. Әгәр моны үти алмыйсың икән, бу эшкә алынма. Яки саткач, акчасын фәлән вакыттан соң бирермен дип, алдан ук вәгъдә биреп, килештер.



*Сиксәненче тәрбия*

## ХӘЛӘЛ СӘҮДӘ БЕЛӘН АЛЫНГАН БЕР ТИЕНЕҢ УН ТИЕН ХӘРАМЫҢНАН ӨСТЕН

Һөнәрле кол үлмәс. Әй дустым, һөнәрең нинди булса да, үзең яхшы булсаң, акча китерә. Әгәр кулыңда бераз акчаң булса, сәүдә белән шөгыльләнү — яхшы кәсеп. Ләкин шәригать кушканча сәүдә алып бару — бик авыр эш. Әмма син, дустым, тырыш. Хәләл юл белән алынган бер тиенең ун тиен хәрамыңнан өстен. Сәүдә итәр өчен малның яхшысын ал, чөнки аны сатып файда алуга өмет зур, начар нәрсәң сатылмый калып, зыян килер.



*Сиксән беренче тәрбия*

## САТУ-АЛУ ЭШЕНДӘ ЯЛГАН СӨЙЛӘМӘ, АНТ ИТМӘ

Һәм тагын, дустым, адәм һәм хайван ризыгы белән сату-алу итмә. Ягъни икмәкне, ашлыкны арзан вакытта сатып алып, кыйммәтләнгәч, юклык һәм ачлык вакытында, сатармын дип саклау — хәрам. Моны спекуляция диләр, һәм тагын, дустым, сату-алу эшендә ялган сөйләмә, ант итмә. Сатуны-алуны җиңелләштер. Шулай ук кем белән булса да сәүдә итүдән саклан: дөньяда гадел кеше бик аз, ызгыштан башың чыкмас. Сынамаган, белмәгән мал белән сату итмә; үзеңнең өйрәнгән сәүдәңне ташлама.



*Сиксән икенче тәрбия*

## АХМАК ҺӘМ НАДАН АДӘМ ДУСЛЫККА ДА, ДОШМАНЛЫККА ДА ЯРАМАС

Әй дустым, акыллы дошман надан дустан яхшырак. Ахмак һәм надан адәм дуслыкка да, дошманлыкка да ярамас. Шулай ук һөнәрсез кеше белән дуслашма. Бернәрсә белмичә, үзен галим, белдеклегә санаган кешедән саклан. Эшең беренче тапкырдан барып чыкмаса, икенче мәртәбә аңа тотынма һәм кулыңнан килмәгәнгә керешмә.

---

[1] «Акыллы дошман надан дустан яхшырак» мәгънәсендә.



*Сиксән өченче тәрбия*

## ӘГӘР ДОШМАН СЕРЕМНЕ БЕЛМӘСЕН ДИСӘҢ, АНЫ ДУСТЫҢА ДА ӘЙТМӘ

Әй дустым, төче ялганнан ачы хакыйкать яхшы. Әгәр дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә.

Олыны олы ит, кечеләргә шәфкатьле бул.

Надан һәм һөнәрсез кешеләрне исәнгә санама, мәет дип бел.

Бер эшне ике мәртәбә эшләмә.




*Сиксән дүртенче тәрбия*

## ҮЗЕҢНӘН ТҮБӘН ДӘРӘҖӘДӘГЕЛӘРГӘ МОХТАҖ БУЛУДАН САКЛАН

Саран кешенең икмәген ашауга карганда ач торуың яхшырак.

Сыналмаган һәм аз белгән кешеңә ышанырга курык, ул сиңа зур игътибар күрсәтсә дә.

Үзеңнән түбән дәрәҗәдәгеләргә мохтаҗлыгың төшүдән саклан — моннан кыен эш юктыр. Бурычка кермә: кешегә бурычлы булуың аңа коллыкка эләгү дигән сүз.



*Сиксән бишенче тәрбия*

## УРЛАНГАН НӘРСӘНЕ БЕЛӘ ТОРЫП АЛУ ҮЗЕҢ УРЛАГАНГА ТИҢ

Әй дустым, урланган нәрсәне алудан саклана күр. Ул үзең урлаганга тиң. Урланган әйбер ялгышлык белән кулыңа керсә, үзеңдә калдырма, иясенә тапшыра күр.



*Сиксән алтынчы тәрбия*

# ДУС БУЛЫП КЫЛАНЫП, ЭЧЕНДӘ ДОШМАНЛЫК ҺӘМ КӨНЧЕЛЕК ЯШЕРЕП ЙӨРГӘН КЕШЕДӘН БИК САКЛАН

Әй дустым, тышыннан дуслык күрсәтеп, эчендә дошманлык һәм көнчелек яшереп йөргән кешедән бик саклан. Бу заманның дусларына да ышанма. Берәү сине алдыңда мактаса, белеп тор, һичшиксез, сине артыңда яманлап йөри. Сына, үзеңне алдарга бирмә.



*Сиксән җиденче тәрбия*

## ЯХШЫ СҮЗ БЕЛӘН ЯВЫЗНЫ ХАК ЮЛГА САЛЫРМЫН, ДИМӘ

Әй дустым, усалны яхшы сүз белән туры юлга күндерермен, димә.

Ахмак үз-үзенә китергән зарарны акыллы адәм дошманына да күрсәтмәс.

Әгәр, дустым, сине алдыңда мактасалар һәм яхшылыгың өчен сиңа рәхмәт әйтсәләр: «Һай рәхмәт! Мине мактыйсыз икән ләбаса», — димә, сүзсез тыңла.

Әгәр дусларым күп булсын дисәң, кеше эшенә катышма һәм һичкемгә бәйләнмә — барысы да сиңа дус булыр.



*Сиксән сигезенче тәрбия*

## ХЕЗМӘТЕҢ МИКЪДАРЫНЧА ГЫНА ХАКЫН АЛЫРГА ӨМЕТЛӘН


Әй дустым, булмастайны өмет итмә. Хезмәтең микъдарынча гына хакын алырга өметлән. Мәсәлән, ун тиенлек эш башкарып, ун сум көтү урынсыз. Белмәгән эшеңә тотынма.



*Сиксән тугызынчы тәрбия*

## КЕШЕНЕҢ КҮҢЕЛЕН ЯРАЛЫЙ ТОРГАН СҮЗНЕ ТЕЛЕҢӘ КИТЕРМӘ


Әй дустым, кешенең күңелен яралый торган сүзне телеңә китермә. Бер сүзне искәрмәстән әйтерсең дә, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, үпкәләр. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан.



*Туксанынчы тәрбия*

## КЕШЕНЕҢ ГАЕБЕН ХАЛЫК АЛДЫНДА ӘЙТМӘ

Әй дустым, кешенең пәрдәсен ертма, ягъни халык алдында аның гаебен йөзенә әйтмә, аны оялтма, бу бик начар гамәл. Кешенең гаебен һәм ярамаган эшен халык алдында әйтү — башына тукмак белән сукканнан да яманрактыр. Синең белән шулай эшләсәләр, яхшы булырмы?



*Туксан беренче тәрбия*

## КУЛ АСТЫҢДАГЫЛАРГА ХЕЗМӘТ ИТКӘН ӨЧЕН ШУҢДА УК АКЧАСЫН БИР

Кул астыңдагыларың һәркайчан канәгать булсын: ягъни җәмәгатеңне һәм хезмәтчеләреңне рәнҗетмә. Хезмәт хаклары булса, тоткарлама, шуңда ук акчасын бир, ризалыкларын ал.

Һәрбер күңелеңә килгән эшне эшләргә ашыкма, соңыннан үкенерлек булмасын — эшеңне уйлап башкар.



*Туксан икенче тәрбия*

## СӘДАКА, ХӘЕР ҺИЧКАЙЧАН КЕШЕНЕ БӨЛДЕРМӘС

Әй дустым, халык каршында дәрәҗәм һәм хөрмәтем зур булсын дисәң, ачык йөзле, икмәкле-тозлы, юмарт бул. Юмарт булуыңнан байлыгың кимемәс, киресенчә артыр. Садака, хәер һичкайчан кешене бөлдермәс. Кешенең ярдәменә мохтаҗ булудан саклан.

Әй дустым, кешегә эшләгән яхшылыгың өчен аннан берни таләп итмә. Үзеңнең хәзинәңдә барына канәгать бул.



*Туксан өченче тәрбия*

## АХМАК ҺӘМ НАДАННАР ЭШЕНӘ КАТЫШМА

Кешедән әйбер алып торып, бурычлы булма. Кешегә бурычлы булсаң, аның колына әйләнәсең.

Ахмак һәм наданнар эшенә катышма, үзеңне кимсетә, хурлый күрмәсеннәр. Алар белән бәхәскә дә кермә, сүз көрәштермә, зирәк Локманның җавабын хәтереңдә тот.



*Туксан дүртенче тәрбия*

## ИНСАН БУЛГАН АДӘМГӘ АШАУ ӘДӘПЛӘРЕН ҮТӘҮ ТИЕШ


Әй дустым, ашаганда бик күп әдәпләр бар. Инсан булган адәмгә аларны үтәү тиеш. Ашың хәләлдән булсын. Ризыкны ашарга утырыр алдыннан һәм ашап туйгач кулыңны ю, ашың бәрәкәтле булыр. Әмма бик кайнар ашау ашама, кайнар ризыкта бәрәкәт аз. Аны хайван шикелле иснәп карама. Кайнар булса, өреп ашама, өреп эчмә — болар әдәпсезлектән саналыр.



*Туксан бишенче тәрбия*

## АШ АЛДЫННАН БИСМИЛЛА ӘЙТ, АШАГАЧ НИГЪМӘТЕҢ ХӘЛӘЛ БУЛЫР

Әй дустым, аш алдыннан бисмилла әйт, ашаган нигъмәтең хәләл булыр. Әмма хәрам нигъмәткә бисмилла әйтү тыела. Ә хәләл нигъмәткә бисмилла әйтмәсәң, ашаган азыгың шайтан белән уртак булыр. Бисмилланы, табын артындагы башка кешеләрнең дә исләренә төшерү буларак, кычкырып әйтү тиеш. Ашап туйгач, «әлхәмделилләһ» дип, шөкер итәргә кирәк. Әмма әле ашап туймаган кешеләрне тукталырга мәҗбүр итмәс өчен, «әлхәмделилләһ» дип эчтән генә әйтү зарур.



*Туксан алтынчы тәрбия*

## ВАК-ВАК ЧӘЙНӘП АША, АШЫҢ ЯХШЫРАК СЕҢСЕН

Әй дустым, ризыкны уң кулың белән аша. Авызыңа тутырып капма. Вак-вак чәйнә, ашың сеңсен. Табынга ашны китергәч, шундук ашарга утыр, ризыкны көттермә. Ашап туйгач, өстәлдән ашны алмас борын торып китмә. Өстәл янына җыелган кешеләрне бер килеп җитмәгән адәм аркасында көттермә.



*Туксан җиденче тәрбия*

## КЕШЕНЕҢ ӨЛЕШЕНӘ ҺӘМ КЕШЕНЕҢ КАШЫГЫНА КҮЗ САЛМА

Ашаган вакытта уңга-сулга карама, алдыңа гына карап утыр. Кешенең өлешенә һәм кашыгына күз салма. Ризыкның уртасыннан алма, табакның үзеңә таба ягындагы читеннән ал. Алдыңа түкмичә һәм тамызмыйча аша. Мәҗлестә хөрмәтле адәмнәр булса, оят булыр. Эт шикелле, шапырдатып һәм тәлинкәннең өстенә ятып ашама, мәҗлестә бу — гаеп эш.



*Туксан сигезенче тәрбия*

## АЗ АШАУДА ФАЙДА БАР, ТӘНЕҢ — СӘЛАМӘТ, ЗИҺЕНЕҢ — САФ, ХӘТЕРЕҢ КУӘТЛЕ БУЛЫР


Әй дустым, мәҗлестә хөрмәтлеләр булса, алардан алда ашка кул сузма, бу әдәпсезлек булыр. Башкалар ашап туйгач, кешедән калып ашап утырма. Күп ашау зарарлы, хайвани гамәл санала, аннан төрле авырулар пәйда була. Аз ашауда файда бар, тәнең — сәламәт, зиһенең — саф, хәтерең яхшы булыр.



*Туксан тугызынчы тәрбия*

## БАР НИГЪМӘТЕҢНЕ КУНАКЛАРЫҢ АЛДЫНА АЧЫК ЙӨЗ БЕЛӘН КУЙ

Әй дустым, әгәр кунак чакырып сыйласаң, кешең аз булса, бергә утырып аша, әгәр кешең күп икән, утырмыйча үзең хезмәт күрсәт. Әмма кунакларыңны ташлап чыгып йөрмә. Аларны гаҗиз булырлык итеп кыстама. Бар булган нигъмәтеңне алларына ачык йөзең белән куй. Килгән кешеләр янында җәмәгатеңне һәм хезмәтчеләреңне ачуланма, орышма. Шулай ук кунакларың белән аралаш, ят кеше кебек йөрмә.


1
2
3

*Йөзенче тәрбия*

## БЕР-БЕРЕНӘ ДОШМАН КЕШЕЛӘРНЕ БЕР МӘҖЛЕСКӘ ҖЫЙМА, БЕР ТАБЫНГА УТЫРТМА


Әй дустым, кунаклар чакырырга уйласаң, бер-беренә дошман кешеләрне бер мәҗлескә җыйма, бер табынга утыртма. Кунакларны дәрәҗәләренә карап, төркемләп, төрле урыннарга утырт.



*Йөз икенче тәрбия*

## ИГЕЛЕКНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛМӘГӘННӘРГӘ КЫЛГАН ИЗГЕЛЕГЕҢ ӘРӘМГӘ КИТӘЧӘК

Әй дустым, белмәгән һәм сыналмаган танышларыңнан саклан. Кеше белән кеше арасында әхлак ягыннан аерма бик күп төрле була. Игелекнең кадерен белмәгәннәргә кылган изгелегең әрәмгә китәчәк. Күркәм холык ияләренә хөрмәт һәм изгелек күрсәтсәң, алар сиңа кол булырлар. Әгәр изгелек кадерен белмәгәннәргә хөрмәт һәм изгелек күрсәтсәң, шөкер итмәсләр, кирелекләрен арттырырлар. Андыйлар: «Карале, мин мондый изгелекләргә хаклы икәнмен ләбаса. Миңа әле тагын фәлән нәрсә, фәлән нәрсә кирәк иде», — дип таләп итеп, дәгъваларын арттыра барып, сине үзләренең колына әйләндерерләр.



*Йөз өченче тәрбия*

## КАРТЛАРНЫ ХӨРМӘТЛӘ ҺӘМ ОЛЫЛА, ҮЗЕҢНӘН КЕЧКЕНӘЛӘРГӘ МӘРХӘМӘТ ҺӘМ ШӘФКАТЬ КЫЛ

Әй дустым, һәркем янында ачык йөз белән йомшак сөйләш, яхшы кешеме, яманмы, мөселманмы яки башка дин тотучымы — һич аерма. Аллаһ Тәгалә Муса галәйһис-сәламгә: «Фиргавен белән йомшак сөйләш», — дип әмер бирде. Картларны хөрмәтлә һәм олыла, үзеңнән кечкенәләргә мәрхәмәт һәм шәфкать кыл. Болай эшләмәсәң, син иманлы кеше булмассың. Гарәпчә укый башлагач, бу сүзләрне хәдис китапларында күрерсең әле.



*Йөз дүртенче тәрбия*

## КАРДӘШЛӘРЕҢ, ДУСЛАРЫҢ БЕЛӘН ҺӘРВАКЫТ КҮРЕШЕП ТОР, АРАЛАР ӨЗЕЛМӘСЕН

Туганнарың, дусларың белән еш йөреш, араларыгыз өзелмәсен. Ягъни бик сирәк тә барма — сине онытмасыннар, көн саен дә барма — синнән туймасыннар... Әй дустым, йөрешсәң, яхшы кешеләр белән йөреш, аралашсаң, яхшы кешеләр белән аралаш.



*Йөз бишенче тәрбия*

## БИШ ТӨРЛЕ КЕШЕНЕ ЮЛДАШ ИТМӘ

Бер акыл иясе үзенең улына: «Әй улым, кем белән телисең, шуның белән сөйләш, аралаш, йөреш, кунакка чакыр, үзең бар. Әмма биш төрле адәмнән читтә тор. Беренчесе — ялганчы кеше белән әңгәмә корма, чөнки аның сүзе су өстендәге язу кебек ышанычлы түгелдер, якынны ераклаштырыр, еракны якынлаштырыр. Шулай ук ахмак һәм надан белән иптәш булма. Чөнки ахмак кеше сиңа файда иткән кебек күренсә дә, чынлыкта аның тырышлыгыннан зыян гына килер. Комсыз кеше белән аралашма. Чөнки ул гел синнән өмет итеп кенә торыр. Саран кеше белән дә юлдаш булма. Чөнки саран кеше сиңа зарардан башка берни китермәс. Әгәр дә аңар хаҗәтең төшсә, сине кимсетер һәм хур итәр. Гомумән, сәфәргә саран кеше белән чыкма. Тагын куркак һәм җебегән кеше белән аралашма, чөнки андыйлар белән һич тынычлык күрмәссең» — диде.



*Йөз алтынчы тәрбия*

## СӘЛАМ БИРСӘҢ ИШЕТТЕРЕП БИР, СӘЛАМ АЛСАҢ ИШЕТТЕРЕП АЛ


Әй дустым бер кавемне күрсәң, сәлам бир. Ягъни бер җирдә күпләп җыелып торган кешеләр төркемен очратсаң, сәлам бирмичә узма. Чөнки ялгыз кеше җыелып торучы бер төркемгә сәламне беренче бирергә тиеш, ә аларга сәламне алып җавап кайтару фарыз — эш... Шулай ук ат белән барган кеше җәяүлегә, җәяү барган кеше утырып торучыга сәлам бирер. Әмма, дустым, сәлам бирсәң ишеттереп бир, сәлам алсаң ишеттереп ал. Ягъни сәламне ишеттереп бирмәсәң, гүя син сәлам бирмәдең, әгәр ишеттереп алмасаң, шулай ук сәламне алмаган кебек була.



*Йөз җиденче тәрбия*

## ӘГӘР ҺИЧКЕМ БУЛМАГАН БЕР ӨЙГӘ БАРЫП КЕРСӘҢ ДӘ, СӘЛАМ БИРУ ТИЕШ

Балаларга сәлам бирүгә карата әйтелгән киңәшләр күп төрле һәм бик каршылыклы. Әмма, бала-чага гына булса да, сәлам бирү хәерле. Әгәр һичкем булмаган бер өйгә барып керсәң дә, сәлам бирү тиеш ләбаса.



*Йөз сигезенче тәрбия*

## КИЕМЕҢ КӨНЧЕЛЕК УЯТЫРЛЫК БУЛМАСЫН

Киемхакындаәйтдисәң,әйдустым,киемең кыйммәтлеме-арзанлымы — тирәңдәгеләрнең киеменнән аерылып тормасын. Ягъни синең кебекләр нинди кием кисә, шундыйны ки. Чөнкиалардакөнчелектуып,синерәнҗетердәй сүзләр әйтүләре ихтимал. Төсләргә килгәндә, шәригатебез ак төскә өстенлек бирә. Шулай ук динебездә башка төсләргә дә һич тыю юк, теләсәң нинди төстәгене ки. Ләкин киемеңнең рәвешенә (фасонына) игътибарлы бул — артык кыйммәтле дә, тәкәбберлек тудырырлык артык зиннәтле дә булмасын.



*Йөз унберенче тәрбия*

## ЙОРТ САЛДЫРСАҢ, БИК ЗУР, БИК БИЕК ТӨЗЕТМӘ


Әй дустым, йорт салдырсаң, бик зур һәм бик биек итмә, үзеңә җитәрлек кенә булсын. Бик зур йортның җайсызлыгы шул ки, дөнья бер урында гына тормый: эшең артка китеп, закладка салуың яки сатуың бар — акчасы җитәрлек сатып алучы табылмас.


1.
2.
3.
1.
2.
3.
4.

*Йөз уникенче тәрбия*

## КЕШЕНЕ ҺӘЛАКӘТКӘ ИЛТКӘН ДҮРТ НӘРСӘ БАР...

Әй дустым, өч нәрсә күңелле шатландырыр һәм акылны сафландырыр: гүзәл хатын, җитәрлек кадәр ризык һәм якын дус, туган. Шулай ук, адәм аны чиктән тыш күп кылса, һәлакәткә илткән дүрт нәрсә бар: фәхешлек, явызлык, отышлы уеннар, эчкечелек.



*Йөз унөченче тәрбия*

## ӘШӘКЕ КЕШЕНЕ МАКТАСАҢ, ХАЛЫК АРАСЫНДА ҮЗ ДӘРӘҖӘҢ ТӨШӘР

Әй дустым, берәү азгыннарга иярсә, ул кешенең дине бөтен булмас.

Әгәр берәү бер әшәке кешене мактаса, халык арасында үз дәрәҗәсе дә төшәр.

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш сүз** ... 3
Беренче тәрбия.
**Һөнәр — ышанычлы байлык** ... 5
Икенче тәрбия.
**Үзеңне яманлаган кешене макта** ... 7
Өченче тәрбия.
**Гыйлем һәм мәгърифәт буйга һәм кыяфәткә карамый** ... 9
Бишенче тәрбия.
**Тиле күзсезләрдән, наданнардан гыйбрәт ал** ... 11
Алтынчы тәрбия.
**Надан, тиле янында йөрсәң, үзең дә шуңа охшый барасың** ... 13
Җиденче тәрбия.
**Кеше иминлек һәм сәламәтлекнең кадерен бер михнәткә дучар булгач белә** ... 15
Сигезенче тәрбия.
**Урынсыз саранлык — файдасыз** ... 17
Тугызынчы тәрбия.
**Үз көчең белән тапкан бер тиенең чит кул биргән мең тиеннән бәрәкәтлерәк** ... 19
Унынчы тәрбия.
**Әңгәмәгә урынсыз тыгылу — әдәпсезлек** ... 21
Унберенче тәрбия.
**Игелек һәм йомшаклык белән мәмләкәтләр яулана** ... 23
Уникенче тәрбия.
**Шик-шөбһә белән кеше өстенә гаеп тагу — хата** ... 25
Унөченче тәрбия.
**Ахирәттә йөзеңә чыгарлык гамәлләр эшләмә** ... 27
Ундүртенче тәрбия.
**Фәкыйрьләрне хөрмәтләү, аларны якын иту — әҗерле** ... 29
Унбишенче тәрбия.
**Кара күңелгә үгет-нәсихәт үтми** ... 31
Уналтынчы тәрбия.
**Акыллы бәндә өчен адым саен гыйбрәт бар** ... 33
Унҗиденче тәрбия.
**Корсакны күп тутыру файдага түгел** ... 35
Унсигезенче тәрбия.
**Җан ияләреннән гыйбрәт алып, зикер-тәсбих әйтеп яшә** ... 37
Унтугызынчы тәрбия.
**Дәрвишкә зиннәт килешми** ... 39
Егерменче тәрбия.
**Тормышта канәгать булып, гыйлем җый** ... 41
Егерме беренче тәрбия.
**Корсагың тулганчы ашама, аз белән канәгать бул** ... 43

Егерме икенче тәрбия.
**Үз нәфесен җиңүче генә баһадир була** ........ 45
Егерме өченче тәрбия.
**Фәкыйрьлек теләнеп йөрүдән хәерлерәк** ........ 47
Егерме дүртенче тәрбия.
**Нәфесен тыймаган кеше авырлыкларга чыдамый** ........ 49
Егерме бишенче тәрбия.
**Күп ашау — исраф** ........ 51
Егерме алтынчы тәрбия.
**Бәхет байлыкта түгел** ........ 53
Егерме җиденче тәрбия.
**Байлык бозыклыкка юл ача** ........ 55
Егерме сигезенче тәрбия.
**Синнән мохтаҗракларны, гарипләрне күреп гыйбрәт ал** ........ 57
Егерме тугызынчы тәрбия.
**Балыкчы үзенә насыйп булмаган балыкны тота алмый** ........ 59
Утызынчы тәрбия.
**Берәүнең кайгысын күреп, беркайчан да сөенә күрмә** ........ 61
Утыз беренче тәрбия.
**Бернәрсәне тәмам нигезенә төшенеп белмәсәң, бу хакта сүз башлама** ........ 63
Утыз өченче тәрбия.
**Бай балаларын кырысрак тәрбияләргә кирәк** ........ 65
Утыз дүртенче тәрбия.
**Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәк кебек** ........ 67
Утыз бишенче тәрбия.
**Тәрбия бердер, ләкин сәләтлелек төрле** ........ 69
Утыз алтынчы тәрбия.
**Кем улы булуың түгел, гамәлең мөһим** ........ 71
Утыз җиденче тәрбия.
**Балаң бар икән, аңа яхшы тәрбия бирергә дә кирәк** ........ 73
Утыз сигезенче тәрбия.
**Нәфес дошманнан яманрак** ........ 75
Утыз тугызынчы тәрбия.
**Явыз бәхеттән саклан** ........ 77
Кырыгынчы тәрбия.
**Берәү сиңа изге нәсихәт кылса, ул өйрәткәнчә гамәл кыл** ........ 79
Кырык беренче тәрбия.
**Туплаган гыйлемең белән гамәл кыл** ........ 81
Кырык икенче тәрбия.
**Дустың бервакыт — дошманга, ә дошманың дустыңа әйләнергә мөмкин** ........ 83
Кырык өченче тәрбия.
**Хәтта дивар янында сөйләсәң дә, акыл белән сөйләш, дивар артында колак булмасын** ........ 85
Кырык дүртенче тәрбия.
**Куәтең барында изгелек кыл** ........ 87

Кырык бишенче тәрбия.
**Җиде төрле кешедән киңәш алма** ........ 89
Кырык алтынчы тәрбия.
**Исемеңне мактап телгә алсыннар**........ 91
Кырык сигезенче тәрбия.
**Саулыкның кадерен бел** ........ 93
Кырык тугызынчы тәрбия.
**Ни чәчсәң, шуны урырсың**........ 95
Илленче тәрбия.
**Саран кеше үз малының каравылчысы гына ул** ........ 97
Илле беренче тәрбия.
**Яман холыклы кешегә гамәлең белән нәсихәт кыл** ........ 99
Илле икенче тәрбия.
**Яхшылыкның кадерен белмәгән кешедән ерак йөр** ........ 101
Илле өченче тәрбия.
**Әҗәл көтмәгәндә килергә мөмкин** ........103
Илле дүртенче тәрбия.
**Саф күңелле, күркәм фигыльле кеше хөрмәт-ихтирамга лаек** ........105
Илле бишенче тәрбия.
**Гафу итә белү — иң күркәм сыйфат** ........107
Илле алтынчы тәрбия.
**Мохтаҗга үзе сораганчы ярдәм күрсәт** ........109
Илле җиденче тәрбия.
**Игелегеңне искә төшермә**........ 111
Илле сигезенче тәрбия.
**Тар холыклы кешенең ризыгы да тар** ........ 113
Илле тугызынчы тәрбия.
**Хәләл кәсептән килгән малны хәрамга сарыф кылырга ярамый**........ 115
Алтмышынчы тәрбия.
**Сиңа изгелек кылган кешегә яманлык эшләмә** ........117
Алтмыш беренче тәрбия.
**Залимнәргә ярдәм итүче — залимнәрнең берседер**........ 119
Алтмыш икенче тәрбия.
**Акыллы булып кыланып, урынсыз җирдә нәсихәт кылырга маташма** ........ 121
Алтмыш өченче тәрбия.
**Алыш-биреш — башка, кардәшлек — башка** ........123
Алтмыш дүртенче тәрбия.
**Яхшы һәм йомшак сүзгә кешенең күңеле эреп китә** ........125
Алтмыш бишенче тәрбия.
**Ашыгып эш кылган кеше үкенеч тарымый калмас** ........127
Алтмыш алтынчы тәрбия.
**Бер җиргә кергәнче, әүвәл аннан ничек чыгасыңны уйла** ........129
Алтмыш җиденче тәрбия.
**Бер мәртәбә ялганласаң, чын сүзеңә дә ышанмаслар...** ........ 131

Алтмыш сигезенче тәрбия.
**Яман холыклы затлардан ерак йөр, күркәм холыклы затлардан аерылма** ........ 133
Алтмыш тугызынчы тәрбия.
**Авызыңнан чыккан кире кайтмас** ........ 135
Җитмешенче тәрбия.
**Акыл белән тотсаң, аз нәрсә дә бәрәкәтле** ........ 137
Җитмеш беренче тәрбия.
**Хөрмәт һәм дан озын буй, юан корсак белән түгел, ә тырышлык белән яулана** ........ 139
Җитмеш икенче тәрбия.
**Гыйлем иясе белән сөйләшү ислемай сатучы янында торган кебек** ........ 141
Җитмеш өченче тәрбия.
**Кешенең эшендә яки сүзендә хата күрсәң, төзәтмә** ........ 143
Җитмеш дүртенче тәрбия.
**Файда китерергә кулыңнан килми икән, зарарың булса да тимәсен** ........ 145
Җитмеш бишенче тәрбия.
**Малны саклау аны табу белән җыюдан авыррак** ........ 147
Җитмеш алтынчы тәрбия.
**Чыгымнарын санап тоткан кеше мохтаҗ булмый** ........ 149
Җитмеш җиденче тәрбия.
**Әманәтне үз малың кебек итеп сакла** ........ 151
Җитмеш сигезенче тәрбия.
**Кемгә бурычлы булсаң, шуңа коллыкка төшәрсең** ........ 153
Җитмеш тугызынчы тәрбия.
**Әгәр бер кеше сиңа әманәт бирергә теләсә, үзеңә бәла алма** ........ 155
Сиксәненче тәрбия.
**Хәләл сәүдә белән алынган бер тиенең ун тиен хәрамыңнан өстен** ........ 157
Сиксән беренче тәрбия.
**Сату-алу эшендә ялган сөйләмә, ант итмә** ........ 159
Сиксән икенче тәрбия.
**Ахмак һәм надан адәм дуслыкка да, дошманлыкка да ярамас** ........ 161
Сиксән өченче тәрбия.
**Әгәр дошман серемне белмәсен дисәң, аны дустыңа да әйтмә** ........ 163
Сиксән дүртенче тәрбия.
**Үзеңнән түбән дәрәҗәдәгеләргә мохтаҗ булудан саклан** ........ 165
Сиксән бишенче тәрбия.
**Урланган нәрсәне белә торып алу үзең урлаганга тиң** ........ 167
Сиксән алтынчы тәрбия.
**Дус булып кыланып, эчендә дошманлык һәм көнчелек яшереп йөргән кешедән бик саклан** ........ 169
Сиксән җиденче тәрбия.
**Яхшы сүз белән явызны хак юлга салырмын, димә** ........ 171
Сиксән сигезенче тәрбия.
**Хезмәтең микъдарынча гына хакын алырга өметлән** ........ 173

Сиксән тугызынчы тәрбия.
**Кешенең күңелен яралый торган сүзне телеңә китермә** ............ 175
Туксанынчы тәрбия.
**Кешенең гаебен халык алдында әйтмә** ............ 177
Туксан беренче тәрбия.
**Кул астыңдагыларга хезмәтләре өчен шунда ук түлә** ............ 179
Туксан икенче тәрбия.
**Сәдака, хәер һичкайчан кешене бөлдермәс** ............ 181
Туксан өченче тәрбия.
**Ахмак һәм наданнар эшенә катышма** ............ 183
Туксан дүртенче тәрбия.
**Инсан булган адәмгә ашау әдәпләрен үтәү тиеш** ............ 185
Туксан бишенче тәрбия.
**Аш алдыннан бисмилла әйт, ашагач нигъмәтең хәләл булыр** ............ 187
Туксан алтынчы тәрбия.
**Вак-вак чәйнәп аша, ашың яхшырак сеңсен** ............ 189
Туксан җиденче тәрбия.
**Кешенең өлешенә һәм кешенең кашыгына күз салма** ............ 191
Туксан сигезенче тәрбия.
**Аз ашауда файда бар, тәнең — сәламәт, зиһенең — саф, хәтерең куәтле булыр.** ............ 193
Туксан тугызынчы тәрбия.
**Бар нигъмәтеңне кунакларың алдына ачык йөз белән куй** ............ 195
Йөзенче тәрбия.
**Бер-беренә дошман кешеләрне бер мәҗлескә җыйма, бер табынга утыртма** ............ 197
Йөз икенче тәрбия.
**Игелекнең кадерен белмәгәннәргә кылган изгелегең әрәмгә китәчәк** ............ 199
Йөз өченче тәрбия.
**Картларны хөрмәтлә һәм олыла, үзеңнән кечкенәләргә мәрхәмәт һәм шәфкать кыл** ............ 201
Йөз дүртенче тәрбия.
**Кардәшләрең, дусларың белән һәрвакыт күрешеп тор, аралар өзелмәсен** ............ 203
Йөз бишенче тәрбия.
**Биш төрле кешене юлдаш итмә** ............ 205
Йөз алтынчы тәрбия.
**Сәлам бирсәң — ишеттереп бир, сәлам алсаң — ишеттереп ал** ............ 207
Йөз җиденче тәрбия.
**Әгәр һичкем булмаган бер өйгә барып керсәң дә, сәлам бирү тиеш** ............ 209
Йөз сигезенче тәрбия.
**Киемең көнчелек уятырлык булмасын** ............ 211
Йөз унберенче тәрбия.
**Йорт салдырсаң, бик зур, бик биек төзетмә** ............ 213
Йөз уникенче тәрбия.
**Кешене һәлакәткә илткән дүрт нәрсә бар** ............ 215
Йөз унөченче тәрбия.
**Әшәке кешене мактасаң, халык арасында үз дәрәҗәң төшәр** ............ 217

Просветительское издание

Каюм **Насыри**

**Книга о воспитании**

Издание выполнено в просветительских целях

**Руководитель проекта**
Азат Ганиев

**Шеф-редактор**
Алсу Низамеева

**Литературная редакция**
Ильгизар Закиев, Лейсан Гарфеева, Фарида Ахметзянова

**Художественный редактор**
Сергей Киатров

**Художники-иллюстраторы**
Марс Фархутдинов, Алиса Егорова, Анна Гаранина, Максим Рахмачёв

**Графическая вёрстка**
Елены Шараповой

**Руководитель IT отдела**
Дамир Бариев

**Веб-дизайн**
Рамазан Нуруллин

**Технический директор**
Ильдар Низаметдинов

**Административная группа**
Анна Кудрявцева, Асия Галеева, Олег Попов, Георгий Шилов, Яна Смоленцева

Подписано в печать 03.04.2024. Формат 70x100/16. Печать офсетная. Тираж 27 500 экз. Заказ №
Отпечатано в типографии ООО «ЛД-ПРИНТ»
196643, Россия, Санкт-Петербург, Колпинский р-н, пос. Сапёрный, ш. Петрозаводское д. 6, стр. 6
Тел. (812) 462-83-83, e-mail: office@ldprint.ru

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

Татарское детское издательство.
420047, г. Казань, ул. 3-я Армавирская, 8.
www.tdpress.ru



## Каюм Насыйри

(1825–1902)

**күренекле татар мәгърифәтчесе, галим һәм язучы**

Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Югары Шырдан (хәзер — Кече Шырдан) авылында туа.

Бу могтәбәр затның эшчәнлеге күпкырлы: аның әдәбият, тел белеме, математика, медицина, педагогика, тарих, география өлкәләренә караган фәнни хезмәтләре билгеле. Каюм Насыйри татар әдәбияты үсешенә дә зур өлеш кертә. Әдип — «Кырык бакча», «Китаб-әт-тәрбия», «Әхлак рисаләсе», «Әбүгалисина кыйссасы», «Кырык вәзир» һ.б. әсәрләр авторы. Каюм Насыйри дөньяви юнәлештәге татар педагогик фикеренә нигез салучыларның берсе булып санала.

## Каюм Насыри

(1825–1902)

**выдающийся татарский просветитель, учёный и писатель**

Каюм Насыри (Габделькаюм Габденнасырович Насыров) родился в селе Верхний Ширдан (ныне село Малые Ширданы) Зеленодольского района Республики Татарстан.

Деятельность просветителя многогранна: известны его научные труды в области литературы, языкознания, математики, медицины, педагогики, истории, географии. Каюм Насыри внёс большой вклад в развитие татарской литературы. Он является автором таких произведений, как «Сорок садов», «Книга о воспитании», «Трактат о нравственности», «Сказание об Абугалисине», «Сорок визирей» и многих других. Каюм Насыри является одним из основоположников татарской педагогической мысли светской направленности.

ТОИ
ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
www.tdpress.ru

каюмнасыйри.рф

ISBN 978-5-6050160-2-1
9 785605 016021 >